# Күкнең җиденче катында

Балалар һәм яшүсмерләр газетасы
Февраль, 2021

Сөекле Татарстаныбызда дүрт миллионга якын кеше яши. Күпчелеген татарлар һәм руслар тәшкил итә. Шулай ук чуашлар, марилар, удмуртлар, мордвалар һ.б. халык вәкилләре дә бар.

Татарстан халыклары үзара бәйләнешләр нәтиҗәсендә, тел, мәдәният һәм башка өлкәләрдә бер-берсенә йогынты ясап, күркәм тормыш итәләр. Аларның киләчәккә омтылышлары, уй-хыяллары охшаган кебек. Татар шагыйре Һади Такташ үзенең шигырендә:

«... нинди охшаганбыз,
Ничек охшаганбыз,
Бертуганнар дисәң,
Мин - Тамбовтан, ә син –
Казан артыннан;
Мин бер мишәр улы, кыргый үскән,
Ә син
Күрше чуваш халкыннан...», - дип язган.

Мәктәбебездә "Халыклар дуслыгы" дип аталган, 5-11 сыйныфлар катнашуында, фестиваль-кичә уздырылды. Һәр сыйныф бер милләт вәкиленең җыр-биюен, гореф-гадәтен, милли киемнәрен, милли үзенчәлекләрен күрсәттеләр.

Бәйрәм күтәренке рухта, күңелле һәм мәгънәле узды.







# Муса Җәлилнең тууына 115 ел

**Муса Җәлил...**

Бу исем һәркемгә кечкенәдән үк яхшы таныш. Шагыйрь, сугышчы, көрәшче, Бөек Ватан сугышы каһарманы.

“...Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм яшәргә кыю ир булып.
Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып,» - дип язды ул үзенең “Җырларым” шигырендә. Чыннан да, бу сүзләр шагыйрьнең тормыш һәм иҗатының эпиграфы булып яңгырый.




Татар дөньясы һәр елның 15 нче февралендә сөекле улы, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең туган көнен билгеләп үтә. Быел да, шагыйрьнең туган көнендә, мәктәбебездә аңа багышланган төрле чаралар узды.

5-11 нче сыйныфлар өчен “М.Җәлил һәм аның көрәштәшләре” дигән күргәзмәгә экскурсия үткәрелде.

ТРның Дәүләт архивы һәм “Гасырлар авазы” журналы редакторлары, Гыйләҗев И.А белән берлектә, шагыйрьнең тормышы һәм иҗатына багышланган кичә уздырылды.



Укучылар кичәгә бик нык әзерлек белән килгәннәр: бөтен сорауларга да төгәл, тулы җаваплар бирделәр, шагыйрьнең шигырьләрен сөйләделәр, эзләнү эшләрен тәкъдим иттеләр. Кичәнең азагында әдипнең биографиясенә кагылышлы өзекләр белән таныштылар. Килгән кунаклар укучыларга рәхмәт әйтте һәм укуларында уңышлар теләде.

**Габдуллаҗанова А.Ф., татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

# Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге көне



Туган телем – иркә гөлем... Күпме мәгънә ята бу сүзләрдә. Һәрбер кеше үз туган телен хөрмәт итеп яшәргә тиештер ул.

Шул уңайдан безнең мәктәптә дә Туган тел Һәм халык бердәмлегенә багышланган кичәләр уздырыла.



26 нчы февраль көнне, татар һәм инглиз телендә, “Том Сойер” һәм “Шалкан” спектакльләре күрсәтелде.

26 нчы февраль көнне 5-11 нче сыйныф укучылары "Живая классика" дигән Бөтен Рәсәй бәйгесенең мәктәп этабында катнаштылар. Укучылар проза әсәрләреннән өзекләр сөйләделәр.




Бәйрәм бик матур узды һәм барлык тамашачыларның күңелендә озакка сакланыр дип уйлыйм.

# 23 нче февраль – Ватанны саклаучылар көне



Россиядә элек–электән үк Ватанны саклаучы иң хөрмәтле һәм изге һөнәр булып саналган. Ватанга хезмәт итү - ул халыкның тыныч тормышын саклау, үз иленең намусын яклау.

Шушы бәйрәм уңаеннан, 20 нче февраль көнне мәктәптә 5-10 нчы сыйныфлар арасында җыр һәм строй смотры үткәрелде. Классларның стройда атлау һәм җырлауларына, формасына карап бәя бирелде.

Без җиңүчеләрне тәбрик итәбез һәм алда да уңышлар телибез.

# 14 нче февраль – Халыкара китап бүләк итү көне



**Ә син беләсеңме, 14нче февраль  Халыкара китап бүләк итү көне икәнен? Әгәр якыннарыңа китап бүләк итсәң  - икеләтә бәйрәм ясарсың.**

Бәйрәмнең идеясе Америкада яшәүче Эмми Бродмурда туган. Аның малае “Ни өчен кешеләрнең бер-берсенә китап бүләк итү көннәре юк?” дип сораган. Хәзер әлеге инициативаны бөтен дөньяда хуплап алганнар. Һәр ел бу бәйрәмне искә алып үтәләр. Мәктәбебездә дә китап бүләк итү матур бер традициягә әйләнде. Укучылар, укытучылар бер-берсенә







ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ
И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В ТАТАРСТАНЕ
2021
ТАТАРСТАНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ
ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

# Спорт яңалыклары...

11 нче февраль көнне 4 нче сыйныфлар арасында “Тизрәк, югарырак, көчлерәк” исемендәге ярыш уздырылды.

Бу чара сәламәт яшәүне пропагандалау максатыннан үткәрелде.

Программада тизлекне, өлгерлекне , көчне тикшерүгә караган ярыш төрләре уздырылды.

Укучылар түземлелекләрен, чыдамлыкларын күрсәтеп, зур нәтиҗәләргә ирештеләр.





1 нче сыйныф укучылары әле кайчан гына мәктәпкә килгәннәр иде.Бер-берсе белән дуслашып та беткәннәр. Бердәмлекләрен алар, “Күңелле старт”лар ярышында исбатладылар.

Өлгер, кыю, җитез балалар төрле биремнәрне үтеп, югары нәтиҗәләргә ирештеләр.

Афәрин! Киләчәктә дә шулай җитез, кыю, сәламәт булып үсегез!

Спартакиада кысаларында узган район күләмендәге өстәл теннисында катнашкан укучы кызларыбызны 3 нче урын яулаулары белән котлыйбыз!

Киләчәктә тагын да югарырак үрләрне яуларга язсын!




## Гәҗитне басмага әзерләделәр:

Баш мөхәррир: Габдуллаҗанова А.Ф.

.

8 а сыйныфы укучылары:
Соколова С.,Сафина К., Овезова Л., Закирова А.